КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 апрель г.Казань № 307

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2016 ел, 9 август, 541 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2016 ел, 9 август, 541 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 февраль, 87 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 746 нчы; 2018 ел, 5 март, 135 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1316 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлекле $3.3.16^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$3.3.16^1$. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган, аларны төзү, саклау һәм файдалану эчке эшчәнлекне оештырганда электрон документлар рәвешендә гамәлгә ашырылырга тиеш булган документлар исемлеген килештерә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин